КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 24 апрель г.Казань № 334

Дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен үзгәртеп төзү турында

Татарстан Республикасында дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан ш., Г.Кутуй ур., 88 йорт адресы буенча урнашкан «Республика медицина мәгълүмати-аналитик үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Республика үзәге), Әлмәт ш., Шоссейная ур., 1б йорт адресы буенча урнашкан «Әлмәт медицина мәгълүмати-аналитик үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Әлмәт үзәге), Түбән Кама ш., Актүбә ур., 9 йорты адресы буенча урнашкан Түбән Кама шәһәренең «Медицина мәгълүмати-аналитик үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Түбән Кама шәһәре үзәге), юридик адресы: Түбән Кама шәһәре, Менделеев ур., 32а йорт, Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык пр., 10 йорт адресы буенча урнашкан Яр Чаллы шәһәренең шәһәренең «Медицина мәгълүмати-аналитик үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Яр Чаллы шәһәре үзәге) – Әлмәт үзәген, Түбән Кама шәһәре үзәген, Яр Чаллы шәһәре үзәген Республика үзәге эшчәнлегенең төп максатларын саклап, Республика үзәгенә кушу формасында үзгәртеп төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Республика үзәге тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү, шулай ук учреждениеләрне үзгәртеп төзү буенча чараларны финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Республика үзәген гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

2019 елның 15 ноябренә кадәр әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп төзү белән бәйле чараларны законнарда каралганча үткәрүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп төзү чаралары нәтиҗәсендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүе законнар нигезендә тэмин итәргә;

2019 елның 15 ноябренә кадәр Республика үзәге уставы белән каралган төп эшчәнлек нигезендә Республика үзәге өчен дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертергә;

Уставка тиешле үзгәрешләр керткән һәм Республика үзәгенең күзәтүчеләр советларын составларын раслаганнан соң 10 көн эчендә Республика үзәге тарафыннан дәүләт мөлкәтен оператив идарә хокукында теркәү өчен кирәкле документларны, шул исәптән күчемсез милек объектларына техник документларны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшыруны тәэмин итәргә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру белән бәйле чаралар үткәргәннән соң эштән азат ителә торган акчаларны Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга юнәлдерүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

Республика үзәге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 90 көн эчендә элек даими (вакыты чикләнмәгән) идарә итү хокукында Әлмәт үзәге, Түбән Кама шәһәре үзәге, Яр Чаллы шәһәре үзәгендә булган җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) идарә итү хокукында учреждениеләргә бирергә;

Республика үзәге уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә элек оператив идарә хокукында Әлмәт үзәге, Түбән Кама шәһәре үзәге, Яр Чаллы шәһәре үзәгенә беркетелгән дәүләт мөлкәтен, шул исәптән аеруча кыйммәтле мөлкәтне оператив идарә хокукында учреждениеләргә беркетергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә әлеге карарның 3, 4 пунктларын үтәгәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы «2019 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 820 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

карар эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә. бу карарның 1 пунктына ....

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин